КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 10 июнь г.Казань № 785

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 27 июль, 659 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммерциягә карамаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләрен, шулай ук 2019 елның 1 гыйнварына кадәр гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыгын алып бару өчен оештырылган коммерциягә карамаган оешмаларны тәэмин итә торган электр челтәре хуҗалыгы объектларын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммерциягә карамаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләрен, шулай ук 2019 елның 1 гыйнварына кадәр гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыгын алып бару өчен оештырылган коммерциягә карамаган оешмаларны тәэмин итә торган электр челтәре хуҗалыгы объектларын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле

чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 27 июль, 659 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 7 июль, 647 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1474 нче; 2023 ел, 19 май, 611 нче; 2024 ел, 14 октябрь, 880 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммерциягә карамаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләрен, шулай ук 2019 елның 1 гыйнварына кадәр гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыгын алып бару өчен оештырылган коммерциягә карамаган оешмаларны тәэмин итә торган электр челтәре хуҗалыгы объектларын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре вәкаләтле органга җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

2.10 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.1 пунктта «сайлап алуны уздыру турында карар кабул ителгән көннән алып өч көн эчендә» сүзләрен «заявкалар бирә башлау датасына кадәр бер көннән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3.31 пункт өстәргә:

«3.3[1]. Сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү, заявкаларны кабул итү тәмамлану датасыннан да соңга калмыйча, әлеге Тәртипнең 3.1 – 3.3 пунктларында билгеләнгән сайлап алуны уздыру турындагы белдерүне формалаштыру тәртибе кебек тәртиптә, түбәндәге шартларны үтәп, гамәлгә ашырыла:

заявкалар бирү срогы мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән алып заявкаларны кабул итү тәмамлану датасына кадәр әлеге срок кимендә өч календарь көн тәшкил итә торган итеп озайтылырга тиеш;

субсидияләр алучылар тарафыннан сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгәндә субсидияләр алучыларны сайлап алу ысулын үзгәртергә рөхсәт ителми;

заявкалар кабул итә башлау датасы җиткәннән соң сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертелгән очракта, сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә әлеге Тәртипнең 3.8 пунктындагы бишенче абзацы нигезендә сайлап алуда катнашучыларның заявкага үзгәрешләр кертү хокукы карала торган нигезләмә кертелә;

заявка биргән сайлап алуда катнашучыларга, «Электрон бюджет» системасыннан файдаланып, сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертү хакында хәбәр ителә.»;

3.5 пунктның уникенче абзацында «әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.10 пунктта «өч» сүзен «ун» сүзенә алмаштырырга;

3.13 пунктның җиденче абзацында татар текстында «комиссия әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы» сүзләрен «комиссия рәисенең һәм комиссия әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы» сүзләренә алмаштырырга;

3.16 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3.20 пунктта:

алтынчы абзацта татар текстында «комиссия әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы» сүзләрен «комиссия рәисенең һәм комиссия әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, мондый үзгәрешләр кертелү сәбәпләре күрсәтелеп, әлеге пунктта билгеләнгән аны формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә әлеге беркетмәнең яңа версияләрен формалаштыру юлы белән сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенең беренче версияләренә имза куелган көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»;

3.23 пунктның алтынчы абзацында татар текстында «» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Граждан кодексының 401 статьясындагы 3 пункты нигезендә» сүзләрен өстәргә;

4.1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия алучыга, шулай ук субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә акча алучы башка юридик затларга алынган субсидия акчасы исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазы, чимал һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алу тыела.»;

4.2 пунктта:

өченче абзацта «шартнамәләр» сүзен «шартнамәләр (килешүләр)» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «шартнамәләр» сүзен «шартнамәләр (килешүләр)» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «субсидияне һәм акчаны кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга, «шартнамәләр» сүзен «шартнамәләр (килешүләр)» сүзләренә алмаштырырга;

6.2 пунктта:

беренче абзацта татар текстында «Субсидия» сүзен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта татар текстында «субсидия» сүзен «субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Килешүдә билгеләнгән срокларда субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешелмәгән очракта, субсидия алучы кичектерелгән һәр көн өчен кире кайтарылырга тиешле субсидия суммасыннан Россия Федерациясе Үзәк банкының пеня исәпләнә башлау датасына гамәлдә булган төп ставкасыннан бер бөтен меңнән өч йөз алтмыш күләмендә пеня (субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешүнең план буенча датасыннан соң килә торган беренче көннән алып субсидияне (субсидиянең бер өлешен) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару көненә кадәр) түли.»;

6.4 пунктта «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин